СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» июнь 2021 ел № 35

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм 2020 елның 31 июлендәге Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә «Санлы финанс активлары, санлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 259-ФЗ номерлы федераль закон, «санлы финанс активлары, санлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында «10.12.202020 ел, № 778 Россия Федерациясе Президенты Указын гамәлгә ашыру чаралары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"», «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 26.12.2020 № 97-ТРЗ ТР Законы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Советы карары:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының "Балтач шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Балтач шәһәр җирлеге Советының 2016 елның 13 апрелендәге 27 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәнең 2 пунктындагы "г" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

г) җир кишәрлеген, күчемсез милекнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында пайларның катнашу өлеше), санлы финанс активларын, санлы валютаны сатып алу буенча алыш-бирешләр кылган акчаларны алу чыганаклары, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы соңгы өч елда хезмәткәрнең һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш кылган акчалар алу чыганаклары турында белешмәләр.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

4. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин